РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КУКМОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН
РАЙОН СОВЕТЫ

**КАРАР** **КАРАР**

2020 елның 7 мае

Кукмара
шәһәре

№ 280

Кукмара муниципаль районы Советының 2005 елның 10 декабрендә кабул ителгән 17 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Советы Регламентына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Уставы нигезендә Кукмара муниципаль районы Советы карар бирде:

Кукмара район Советының 2005 елның 10 декабрендә кабул ителгән 17 номерлы карары белән расланган Кукмара муниципаль районы Советы Регламентына (Кукмара муниципаль районы Советының 2009 елның 12 ноябрендәге 52 номерлы, 2014 елның 14 мартындагы 08 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге эчтәлекле $18^1$ бүлеген өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«$18^1$ бүлек. Югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яки хәрби хәл чорында район Советының эш үзенчәлекләре

$82^1$ статья

1. Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек режимы, гадәттән тыш хәл режимы, чикләү чаралары (карантин), гадәттән тыш яисә хәрби хәл кертелгән чорда Дәүләт Советы Рәисе карары белән Дәүләт Советы, шул исәптән аның Аппараты эшчәнлегенең аерым тәртибе (алга таба – эшчәнлекнең аерым тәртибе) билгеләнергә мөмкин.

2. Эшчәнлекнең аерым тәртибен билгеләнгәндә Район Советы, район Советының даими комиссияләре утырышларын үткәрү, тавыш бирү һәм аларда карарлар кабул итү өлешендә әлеге Регламент нигезләмәләре әлеге бүлектә билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып кулланыла.

3. Аерым эшчәнлек тәртибе гамәлдә булган чорда район Советы, район Советыны даими комиссияләре утырышлары (алга таба – район Советы, район Советының даими комиссиясенең дистанцион рәвештәге утырышы), мәгълүмати-телекоммуникацион элемтә челтәрләреннән файдаланып, видеоконференцэлемтә рәвешендә үткәрелергә мөмкин.

$82^2$ статья

1. Район Советының даими комиссиясе утырышын үткәрү турында карар даими комиссия рәисе тарафыннан район Башлыгының мәҗбүри хәбәрнамәсе белән кабул ителә.

2. Район Советы даими комиссиясенең дистанцион рәвештә уздырыла торган утырышында даими комиссия әгъзалары булмаган затларның катнашуы район Советының даими комиссиясе рәисе карары буенча, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары таләпләрен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

3. Район Советы даими комиссиясе утырышын дистанцион рәвештә уздырганда, карала торган мәсьәлә буенча карар сорашып тавыш бирү юлы белән кабул ителә.

$82^3$ статья

1. Аерым эшчәнлек тәртибе гамәлдә булган чорда, кичектерү мөмкин булмаган аерым очракларда, район Советы даими комиссиясенең алар карамагына кертелгән мәсьәләләр буенча карарлары даими комиссия әгъзаларын сораштыру юлы белән тавыш биреп кабул ителергә мөмкин.

2. Даими комиссия әгъзаларын сораштыру юлы белән тавыш бирү тиешле даими комиссия рәисе карары буенча үткәрелә һәм һәр мәсьәлә буенча даими комиссия әгъзасы позициясе чагылдырыла торган сораштыру кәгазьләреннән файдаланып гамәлгә ашырыла. Сораштыру кәгазе район Советына, шул исәптән электрон элемтә чараларын кулланып җибәрелергә мөмкин.

$82^4$ статья

1. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турында карар район Башлыгы тарафыннан кабул ителә. Утырышны дистанцион рәвештә уздыру турындагы район Башлыгы карарында күрсәтелгән утырышка чакырылган затлар исемлеге билгеләнергә мөмкин.

2. Район Советы утырышын дистанцион рәвештә уздыру турындагы мәгълүмат тиз арада район Советы депутатларына җибәрелә һәм «Интернет» челтәрендә Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырыла.

3. Дистанцион рәвештә уздырылган район Советы утырышында карарлар ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавыш бирү, сорау бирүгә язылу, чыгышларга язылу утырышта катнашучы депутатларны сораштыру юлы белән үткәрелә (кул күтәрү, дистанцион рәвештә уздырыла торган утырыш башында район Советы депутатлары тарафыннан билгеләнгән башка ысуллар).

4. Чакырылган затлар район Советының дистанцион рәвештә уздырыла торган утырышында мәгълүмати-телекоммуникацион элемтә челтәрләреннән файдаланып катнаша ала.

82$^{5}$ статья

1. Район Советы, район Советының даими комиссиясе утырышын дистанцион рәвештә уздырганда, утырыш беркетмәсе рәсмиләштерелә, утырышта рәислек итүче тарафыннан имзалана.

2. Район Советы, район Советы даими комиссиясенең дистанцион рәвештә уздырылган утырышы беркетмәсенә утырыш үткәргәндә кулланыла торган программа чаралары, утырыш башлану һәм тәмамлану вакыты турында, шулай ук әлеге Регламентта каралган башка белешмәләр кертелә. Беркетмәгә утырышның аудио - һәм видеоязмасы теркәлә».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга, шулай ук Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

Район Башлыгы С. Д. Димитриев